Индекс газеты - 52381

## Шәхесләр

# Мохтарият юлбашчысы намазлыкка басты

**Самар өлкә татар милли-мәдәни мохтариятенә өч ел тулды. Мохтариятнең җитәкчесе - Мидхәт углы Минәхмәт Хәлиуллов. Самарда татар хәрәкәтенә чирек гасыр. Шул чорда зур эшләр башкарылды, һәм бу уңышлар татарларның дәрәҗәсен күтәрде. Соңгы өч елда милләт гөмбәзендә яшь эшбатырлар калкып чыкты. Бу - бик куанычлы күренеш.**

Өлкә мохтариятенең өстенлеге бар. Аның юлбашчысы эшкуар гына түгел, әле Самар шәһәр Думасының депутаты да.

Ләкин дә күрсәтелгән ике сыйфат мактауга лаек булса да, төп фактор булып тора алмыйлар.

Минәхмәт Хәлиулловның өстенлеге шунда ки, ул - гаиләдә тирән тәрбия алган егет. Чын ирләр уза торган юлдан тайпылмаган шәхес. Ул олыларны олы итә белә, кечеләрне кече итә белә торган нәзберек психолог.

Салкын канлы.

Кайнар йөрәкле.



Хисләрен яшерә белүче дипломат. Тирә-юнендәгеләрнең фикерен тыңлап, иң дөрес карар кабул итәргә сәләтле җитлеккән ир заты.

Дәүләт күләмендәге сәясәтче буларак, аңа милләтебез ихтыяҗларын аңларга яңа офыклар ача.

Үзеннән өстә булганнарга буйсына белгәнгә, фикердәшләренең тәкъдимнәрен тыңлый белгәнгә, ул һәрвакыт иң уңышлы карарлар кабул итә.

Минәхмәт әфәнде үз тирәсенә акыллы, тырыш, милләт җанлы шәхесләрне туплый алды һәм алар белән дустанә мөнәсәбәтләр урнаштыруга ирешә.

Ул җәмәгать оешмасының рухын аңлап эш итә.

Бу очракта диктаторлык ысулы оешманы озын гомерле итә алмый. Хәлиуллов һәр кешенең потенциалын сиземләп, аңа хәленнән килгән хезмәтне йөкли. Татарга хезмәт иткәндә һәр катламның кирәклеген аңлый.

Мидхәт углы Минәхмәт Хәлиуллов бик тиз үзендә булган бер кимчелекне җиңеп чыкты. Динебез Ислам таләпләрен үтәмәгән ир халыкның әйдаманы була алмый. Бүген ул инде дөнья куып кына яшәми - ул намазчы да. Малның зәкяте акча булса, акылның зәкяте намаз икәнен төшенеп, Ходай Тәгалә кушканнарны үтәргә тырышып яши. Милли лидерның сыйфатлары - ул идеология!

Һәр әгъзага тукталмыйча гына, оешманың мөдире булган Мөхәммәтгали углы Равил Галимовны искә алмый мөмкин түгел. Равил әфәнде - олуг чиновник вазыйфаларының юлын уңышлы үткән булдыклы һөнәрмәнд.

Милли җәмгыятьнең генераторы.

Оператив сыйфатларга ия.

Таләпчән.

Туры сүзле.

Самар өлкә мохтарияте җитәкчесе Минәхмәт Хәлиулловның намазлыкка басуы яшьләребезгә матур күчергечкә әйләнсен иде. Шулай булган очракта Самар мәчетләрендә татар саны артуына шик юк.

*Шамил БАҺАУТДИН.*

# Татар җанлы студентларга акчалата бүләк тараттылар

Самар татар хәрәкәтендә яңа юлбашчы калкып килә - ул Гомәр углы Илйас Шәкүров. Банкир. Икътисади фәннәр докторы. Профессор. "Туган тел" исемле Самар өлкә татар җәмгыяте юлбашчысы, Самар өлкәсендәге татар эшмәкәрләре берлегенең җитәкчесе. «Яктылык» мәктәбендә иганәчеләр шурасы рәисе. Татар радиосын ачу юлында тырышлык күрсәтә. Чираттагы проектының берсе - татар җанлы студентларга грант булдыру.

Самар өлкә Дуслык йортының актлар залында үзенә бер күтәренке рух сизелде. Грант алучылар уналтау булса, аларны күрергә теләүчеләр күбрәк иде.

Акчалата бүләк бирер алдыннан Илйас әфәнде милләт алдында торган бурычларга тукталды. Аның әйтүенчә, Самарның югары уку йортларында биш меңгә якын татар баласы белем ала икән. Бик зур эш башкарылган. Егетләрне-кызларны барлау үзе бер олуг мәшәкать булса, әле бит аларның кафедра, деканат белән элемтәгә керү читенлекләрен истә тотарга кирәк. Ә шартлар кырыс. Студент татар булсын. Студент яхшы укысын. Студент татарча белсен. Студент татар милли хәрәкәтендә катнашсын һәм татар җанлы булсын. Шундый ук әшне техникумнарда да башкарганнар.

Грантның иң зурысы - 25 мең сум.

Тантанага өлкән буын милләтчеләр дә килгән иде. Һәммәсе үз тәҗрибәсеннән чыгып, яшьләргә вәгазь сөйләделәр.

Кырык өч ел буена "Ялкынлы яшьлек" ансамблен җитәкләгән Илгиз Кәлүч юл башында репетицияләрне йорттанйортка йөреп үткәрүләрен сөйләде.

"Азан" гәҗитәсенең мөхәррире Шамил Галимов Самар татарларының паркларда биеп йөрүләрен искә төшерде.

"Туган тел" җәмгыятенең аксакалы Азат Надиров милли хәрәкәтнең уңышларын санап үтте.

"Җәмгыятьтә нинди генә «изм»нар булса да, барчасы да татарга каршы эшләде. Киләчәктә дә татар милләт буларак тик үз көче белән генә сакланып кала ала, "дигән фикерләр дә яңгырады.

Соңыннан Илйас Шәкүров үз акчасына бастырган сүзлекләрне студентларга таратты.

2012 елның татар җанлы студентлары түбәндәгеләр:

Гүзәл Баламбаева,
Рената Дасаева,
Зарина Исмаилова,
Әлфия Кирасирова,
Ринат Сафин,
Солтан Сафин,
Иркәм Әхмәрова,
Юлия Субеева,
Диана Антропова,
Айрат Экономов,
Радик Шәфиев,
Алсу Фәйзуллина,
Элвира Әсәдуллина,
Элвир Агишев,
Фаил Әбҗәлилов.

Студентлар төрле уку йортларыннан булсалар да, күбрәге медицина университетыннан иде. Күрәсең, бу уку йортында узган елны сәхнәдән музыкаль Сабантуйны күрсәтү әзсез калмаган.

Грант алучылар исемлегендә Согуд Гарәбстанында Король Абдалла исемендәге университет студенты Солтан Сафин да бар. Солтан өлкәнең Камышлы авылыннан.

Грант алучылар сәхнәгә күтәрелеп рәхмәтләр әйттеләр, араларында фикерләрен шигъри юлга салучылар да табылды. Күңелләре белән милләтебезгә хезмәт итәргә әзер егетләр һәм кызлар динебез Ислам тәгълиматын үз күрәләр. Араларында намазга якынаеп килүчеләр булуы өмет тудыра.

*Шамил БАҺАУТДИН.*

## Сәламәтлек

# Азканлылыктан иза чиккәннәргә халык дәвалау ысуллары

### Чөгендер + кишер

Ике чөгендер, ике кишерне уып, сокларын сыгарга һәм шуңа 800 г бал кушып болгатырга, һәр көн иртән ач карынга берәр аш кашыгы кабып, аннары бер стакан су эчеп куярга.

### Мумиё

0,2 г мумиены ашар алдыннан көнгә өч тапкыр җылы үлән чәе белән эчәргә.

### Халык медицинасы:

Ике кашык киптерелгән кара карлыганны бер стакан кайнар суда пешереп, 10 минут сүрән утта кайнаталар, бер сәгать тәнәткәннән соң, сөзеп, көнгә дүрт мәртәбә чирек стаканлап эчәләр.

Көнөнә 4-5 тапкыр бер кашык бал белән бутап бер кашык чөгендер согы эчү файдалы.

*Шәехҗан Фәния ХУҖАХМӘТ.*

# Калтыравык авыруы (Паркинсон авыруы)

### Кәбестә

Үсемлек мае салып, чи кәбестә ашарга. Чи кәбестәнең согын сыгып, шуңа су кушып, ач карынга бер аш кашыгы эчәргә дә ярый. Шуны истә тотарга: ашказанында әчелек күп булса, су кушарга кирәкмәс.

Кәбестә согын эчү һәм күзгә салу башның селкенүеннән (Меньер синдромы) файда бирер.

Бу авыруга шулай ук склероздан кулланыла торган барлык чаралар да ярый.

### Люцерна мае һәм орлыгы

Люцерна маен эчү яисә тәнгә сылау кул-аяк калтыраганны бетерер. Шулай ук люцерна орлыгын пешереп, боламыгын кул һәм аякка ябу да файда бирер.

### Мәче борчагы

25 г шифалы мәче борчагын 100 мл суда 10 минут кайнатып, бер сәгать тәнәткәч, 10 г каз мае кушып, авырткан билне, калтыраган кул һәм аякларны уарга.

*Шәехҗан Фәния ХУҖАХМӘТ.*

**Уважаемые читатели!**

**В газете упоминаются имена Всевышнего и Его Пророка, публикуются аяты из Корана, высказывания Пророка и молитвы. Поэтому просим Вас относиться к газете уважительно, не использовать ее в недостойных целях.**

**Точка зрения авторов может не совпадать с мнением редакции.**

**УЧРЕДИТЕЛИ:** Региональное Духовное управление мусульман Самарской области и местная мусульманская религиозная организация Самарская Соборная мечеть.

**Ответственные за выпуск газеты:**
по организационно-финансовым вопросам - **Джавдят ШАРАПОВ,**
по духовно-просветительской части - **Наил СУЛЕЙМАНОВ.**

**Редактор -**
Фарид ШИРИЯЗДАНОВ.
Тел.: 8-937=65-67-616
**932-58-67 (раб.)**
443081, г. Самара, ул. Стара Загора, 54.
Медресе «Нур», 2 этаж, кабинет 26.
**Адрес редакции и издателя:**
443081, г. Самара, ул. Стара Загора, 54.
Медресе «Нур», 2 этаж, кабинет 29.
E-mail: islam-nur@bk.ru

**Ответственный секретарь -** Шамил БАГАУТДИНОВ.
**Корреспондент -** Али СУЛЕЙМАНОВ.
**Верстка и дизайн -** Рамиль НУРЕТДИНОВ.
**Набор -** Гульназ САФИНА.
**Корректор -** Миляуша ГАЗИМОВА.

**Время подписания к печати:**
*по установленному графику - 16 ноября 15:00*
*фактически - 16 ноября 15:00*

**Отпечатано в ОАО «Типография «Солдат Отечества»**
**Адрес: г. Самара, ул. Авроры, 112 Б.**
**Заказ Тираж 2000.**
*Цена свободная.*
Рег. свидетельство ПИ № ТУ63-00111
Индекс газеты - 52381